**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2024 **Чирмешән авылы** № 257

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы муниципаль һәм дәүләт милке җирләрендәге гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итүнең рекреацион зоналарын булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 03 августындагы 562 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 657-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 03 августындагы 562 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль һәм дәүләт милке җирләрендәге гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итүнең рекреацион зоналарын булдыру һәм алардан файдалану кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2.2 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә «2.2. Гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану Россия Федерациясе Су кодексының 50 статьясы нигезендә раслана торган рекреацион максатларда су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен исәпкә алып, шулай ук шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Район Башкарма комитеты җитәкчесе И.М.Җамалетдинов